# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы  Майна авыл җирлеге составына керүче Баганалы урман хуҗалыгы бистәсе

28 ноябрь 2020 ел. № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының  Майна авыл җирлеге составына керүче  Баганалы урман хуҗалыгы бистәсе торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2021 елда  Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге  чараларга юнәлдерергә:
 - урамнарны яктырту;
 - контейнер мәйданчыгы төзү.
3. Әлеге карарны  Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы, Баганалы урман хуҗалыгы бистәсе, Лесная урамы, 5а санлы йорт адресындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майна авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Гафиятуллин